«Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Чирмешән авыл җирлегенең Чирмешән авылында халык җыены нәтиҗәләре һәм 2026 елда үзара салым кертү турында» 2025 елның “17” ноябрендәге 1 номерлы Татарстан Республикасы Апас Чирмешән авыл җирлегенең Чирмешән авылында гражданнар җыенының карары

«Россия Федерациясе гавами хакимиятенең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә “Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Чирмешән авыл җирлегенең Чирмешән авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән (көндезге формада белем алучы студентлардан, балачактан инвалидлардан, коляскада йөрүче инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, күп балалы гаиләләрдән, мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) гражданнарның, югарыда күрсәтелгән категориядәге гаилә әгъзаларының, махсус хәрби операция барышында хәрби бурычларны иректе үтәүче һәм аларның гаилә әгъзалары тыш) 1000 (бер мең) сум күләмендә 2026 елда үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча

- урамнарны яктыртуны оештыру;
- су белән тәэмин итү һәм су бүлеп бирү системаларын, су башняларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су коймасын тәэмин итә торган башка инженер корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;
- Чирмешән авылы, Буденный һәм Береговая урамындагы торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;
- Чирмешән авылында башка территорияне төзекләндерү ( МТЗ-82.1. тракторына запас частьләр алу, дизель ягулыгы алу, трактористка хезмәт хакы түләү, традицион җирләү урыннарын ремонтлау, төзекләндерү);

эшләрен башкарырга юнәлдерү белән килешәсезме?” дигән мәсьәлә буенча 2026 елның 17 ноябрендә Чирмешән авылы гражданнары җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 252 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 130 кеше .

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен җыенда130 кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар итте:

1.Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Чирмешән авыл җирлегенең Чирмешән авылында халык җыенын узган дип, халык җыенының нәтиҗәләре дөрес дип танырга.

2. “Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Чирмешән авыл җирлегенең Чирмешән авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән (көндезге формада белем алучы студентлардан, балачактан инвалидлардан, колясканда йөрүче инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, күп балалы гаиләләрдән, мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) гражданнарның, югарыда күрсәтелгән категориядәге гаилә әгъзаларының, махсус хәрби операция барышында хәрби бурычларны ирекле үтәүче һәм аларның гаилә әгъзалары тыш) 1000 (бер мең) сум күләмендә 2026 елда үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча

- урамнарны яктыртуны оештыру;
- су белән тәэмин итү һәм су бүлеп бирү системаларын, су башняларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су коймасын тәэмин итә торган башка инженер корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;
- Чирмешән авылы, Буденный һәм Береговая урамындагы торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;
- Чирмешән авылында башка территорияне төзекләндерү ( МТЗ-82.1. тракторына запас частьләр алу, дизель ягулыгы алу, трактористка хезмәт хакы түләү, традицион җирләү урыннарын ремонтлау, төзекләндерү);

эшләрен башкарырга юнәлдерү белән килешәсезме?” дигән мәсьәлә буенча карар кабул ителгән дип танырга.

3.Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Чирмешән авыл җирлегенең Чирмешән авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән (көндезге формада белем алучы студентлардан, балачактан инвалидлардан, колясканда йөрүче инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, күп балалы гаиләләрдән, мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) гражданнарның, югарыда күрсәтелгән категориядәге гаилә әгъзаларының, махсус хәрби операция барышында хәрби бурычларны ирекле үтәүче һәм аларның гаилә

әгъзалары тыш) 1000 (бер мең) сум күләмендә 2026 елда үзара салым кертергә һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча

- урамнарны яктыртуны оештыру;
- су белән тәэмин итү һәм су бүлеп бирү системаларын, су башняларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су коймасын тәэмин итә торган башка инженер корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;

- Чирмешән авылы, Буденный һәм Береговая урамындагы торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;
- Чирмешән авылында башка территорияне төзекләндерү ( МТЗ-82.1. тракторына запас частьләр алу, дизель ягулыгы алу, трактористка хезмәт хакы түләү, традицион җирләү урыннарын ремонтлау, төзекләндерү);

эшләрен башкарырга юнәлдерергә.

4.Әлеге карарны мәгълүмат стендындлары аша халыкка белдерергә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга.

Чирмешән авыл җирлеге Башлыгы А.Т.Зиннатуллин

СОВЕТ ЧЕРЕМШАНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ИНН 1603000736
ЧИРМЕШӘН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ